СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ- СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №153 (7316) | 21 декабрь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

ЯҢАЛЫКЛАР

Кече предприятие

Район үзәк больницасы каршында «Медеус» кече предприятиесе эшләячәк. Ул медицина җиһазлары һәм аппаратураларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау белән шөгыльләнәчәк. Моннан тыш аның планында халыкка хезмәт күрсәтү—ишетү, кан басымы үлчәү аппаратларын, электр-көнкүреш товарларын, телефон аппаратларын ремонтлау да каралган. 4 кешелек яңа берләшмәнең җитәкчесе—Владимир Павлович Сазонов.

Чулпан урман пунктында 10 еллап эшли инде Зәйтүнә Мортазовна Хәбибуллина. Башта инженер иде, инде план бүлеге начальнигы вазифаларын алып бара. Төгәл, гадел Зәйтүнә Мортазовна үз эшенә үтә җаваплы карый, башкалардан да шуны таләп итә. Ә хезмәтен белеп башкара ул. Моңа аның Бутаихада эшләп алган тәҗрибәсе дә, кешеләр белән уртак тел таба белүе дә ярдәм иткәндер, әлбәттә. Шуңа Зәйтүнә Мортазовнаның дәрәҗәсе зур, сүзе һәрчак үтемле.

Рәсемдә: Чулпан урман пункты план бүлеге начальнигы З. М. Хәбибуллина.

✧ Бер колхоз хәбәрләре

ЙОРТ САЛЫНА

Соңгы елларда Урта Чаллы авылында шәхси йортлар салуга, социаль объект корылмаларын төзүгә игътибар артты. Күптән түгел «Яшь көч» колхозы средствосына өчәр бүлмәле ике йорт төзүгә керешелде. Хәзер төзү материаллары ташыла.

КҮРШЕГӘ БУЛЫШАЛАР

Хуҗалыкта өлгер, уңган механизаторларыбыз шактый. Әнәс Мәхмүтов, Рәшит Гатин, Владимир Сакурдаев әнә шундыйлар. Алар куәтле Т-150 тракторларын идарә итәләр, хуҗалыкның иң җаваплы эшләрен башкаралар. Башта басуларга черемә чыгардылар, хәзер шикәр заводына ярдәмгә киттәләр.

В. АБДРӘХИМОВ.

Ишеттегезме әле...

*Украина Югары Советы Президиумы Хорватия республикасының һәм Словения республикасының дәүләт бәйсезлеген танырга һәм алар белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырырга карар итте.

*Румыния Әзәрбайҗанның дәүләт бәйсезлеген таныды һәм бу республика белән халыкара хокук принципларында һәм БМО Уставы нигезендә дуслык элемтәләре урнаштырырга булды.

*Академик С. Шаталин инде икенче тапкыр партиядән чыга. Бу юлы Россия демократлар партиясеннән. Ул бу партиянең Сәяси советы рәисе итеп сайланган иде. Аны бу адымга элекке СССР территориясендә дәүләт һәм сәяси төзелеш мәсьәләләренең хәл ителешеннән ризасызлык этәрде.

*Казан шәһәр Советы Рәисе Р. Гомәров Б. Ельцинга һәм Р. Хасбулатовка хатында өч дәүләт союзының славян характерында булуына басым ясау милләтләр арасында таркаулык китереп чыгарачак, дип кисәтә.

*Украина Мәскәү өчен азык-төлек җибәрә башлады. Министрлар Кабинеты, Президент Кравчукның күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Мәскәүгә 52 мең тонна шикәр, 1,6 мең тонна көнбагыш мае, 2 мең тонна ит һәм ит ризыклары җибәрергә кушты.

*12 декабрьгә илнең 92 аэропортында бензин булмады. Бу барлык һава юлларының яртысы, Украина, Кавказ, Казахстан, Ростов, Краснодар; Сочи аэропортларында самолетлар хәрәкәтсез.

*Бәйсез республика статусы турында игълан иткән Таулы Карабах 12 декабрьдә үзен Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә кабул итүне сорап мөрәҗәгать итте.

*Әрмәнстан халык мәгарифе министры приказы белән, 10 декабрьдән республиканың дистәләгән мәктәбендә дәресләр туктатылды. Сәбәп— мәктәп биналарын җылытыр өчен газ юк.

*Әгәр якындагы араларда инфляциягә каршы кискен чаралар күрелмәсә һәм дәүләт бюджетындагы гаять зур дефицитны кыскартып булмаса, якындагы алты айда баглык товарларга бәяләр 15 тапкыр күтәрелергә мөмкин, дигән фараз ясады СССР Фәннәр академиясенең икътисад институтының бәяләр кую бүлекчәсе мөдире Анатолий Дерябин.

*Элеккеге Советлар Союзы инде 60 миллиардка җиткән бурычларын Германиягә тулысынча түләп бетерә алмас кебек, дип белдерде ГФР бундестагының бюджет комиссиясе рәисе Руди Вальтер.

Очрашу үтте

17 декабрь көнне район Советы бинасында Әфган сугышында һәлак булган сугышчыларның эти-әниләре һәм анда катнашып яра алган егетләр белән сөйләшү үтте. Хөкүмәтебезнең мәгълүм карары нигезендә, әлеге иптәшләргә билгеле күләмдә пособие бирү каралган. Район Советы рәисе урынбасары А. И. Газизуллин килүчеләрне бу карар белән таныштырды, аларның һәртөрле үтенечләрен тыңлады. Сөйләшүгә килгән ата-аналар Колбай Мораса авылыннан Г. Х. Сафиуллина, Яңа Тумбадан А.В. Семенов, Түбән Норлаттан З. Ә. Бакирова, элекке сугышчылар М. Г. Тришин (Сәләнгеш), Р. Ә. Моратов (Норлат) В. Г. Хуснеев (Норлат) бу игътибардан канәгать калдылар. Соңыннан алар өчен аш-чәй табыны да әзерләнгән иде.

Очрашуда район хәрби комиссары Р. Ш. Хафизов, район Советының яшьләр белән эшләү, физкультура һәм спорт бүлеге мөдире Ф. Р. Ногъманова, яшьләр оешмалары район Советы рәисе урынбасары Ә. Х. Шәяхмәтов иптәшләр катнаштылар.

Район потребительләр җәмгыяте җитәкчеләренә, эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре җитәкчеләренә, сәүдә хезмәткәрләренә

АЧЫК ХАТ

Балаларын үстереп, аларның мөстәкыйль тормыш коруларына ирешкән, оныклары өчен әби булырга өлгергән, әмма бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр аяк өсте булган, бернигә дә хокуксыз, өлкән яшьтәге аналар яза бу хатны.

Берсеннән-берсе кечкенә, әле дөньяда гаме булмаган сабыйларын ачы таңнан балалар бакчасына, өлкәннәрен мәктәпкә озатучы, көннәр буе кургаш тузаны иснәп зарарлы цехларда эшләүче һәм әле тагын да балалар табып үстерергә хыялланучы яшь аналар яза.

Илебез үз язмышының авыр мизгелләрен кичерә. Моңа кадәр дә булган андый кыен чаклар. Әмма ул елларда кешеләр кеше өчен терәк була белгәннәр, бу җиһанда гаделлек һәм намус иң югары бәяләнгән. Дөнья авырлыгын, иң кискен мизгелләрдә дә шулар җиңеләйткән. Ул елларда —безнең арада әле сугыш елларын, аннан соңгы дәверне хәтерләүчеләр аз түгел—кешеләр соңгы тәгам ризыкларын да ятимнәр, карт-корылар, авыруча авыр хәлдә калучылар белән бүлешкәннәр.

Ә бүген?! Бүген ничек яшибез соң? Заман кыенлыкларын хәл итүне вакытлыча булса да җиңеләйтү, халыкны дөнья тарафыннан сөйләпә торган ач үлемгә калдырмау хакына район җитәкчелеге кабул иткән карарлар ничек үтәлә соң бездә? Әлеге карарларның үтәлешен тәэмин итүчеләр үз хезмәтләрен ничек башкаралар? Сәүдә җитәкчеләре: «Фәлән мең тонна фәлән ризык, фәлән мең данә фәлән әйбер саттык»,—дип җавап бирергә җыеналармы икән?

Әйе, саттыгыз сез ул кадәр малны, ризыкны! Әмма безгә—гади халыкка, эшче халыкка түгел! Иң аз хезмәт хакы алып эшләүче гади эшче үзенең эш урынында план куганда саттыгыз сез аны. Күз буяу өчен бик аз микъдарын, чират торучы пенсионерларны, инвалидларны сугыштырып(!) кибет эченнән саттыгыз, 1 килолап, 500 граммлап, 250 граммлап, 1 данәләп...Ә бу арада кибет артында җиңел машиналар алышынып кына торды: анда исә сәүдә капчыклап, әрҗәләп, тартмалап барды. Мескен карт-коры кулындагы санаулы талоннарын да тулысынча товарга алмаштыра алмыйча таралышты. Икенче көнне янә дә ил өстендәге имеш-мимешләр буенча кибет чиратына ашыкты.

Бездән—бүгенге көндә үзенә ипи-чәйлек акча эшләүчеләрдән оялмасагыз да шулардан оялыр идегез бәлки? Алар—илебезнең иң кыен чакларында каннарын-җаннарын аямыйча хезмәт куючылар, бүген исә итнең 1 килосы 25 сум булган заманда 180 сум пенсия алучылар—нинди тырышлыклары белән казандылар икән шушы «хөрмәт»не!

Дөрес аңлагыз. Безнең бу хатыбыз — замана авырлыгыннан зарлану түгел. Без сезнең гаделсезлектән, оятсызлыктан гаҗиз булганга күрә язабыз бу хатны.

—Илне нинди хәлгә төшерделәр,—дип хөкүмәтне, ил хуҗаларын гаепләүчеләр дә еш хәзер. Юк, алар кушып эшләткән хәлләр түгел бит бу! Хуҗасызлык, мин-минлек бәласе бу! Кибет киштәләре буш, көндәлек кирәк товарлар әҗәл даруына да юк. Әмма теләсә кайсы кибетнең гап-гади кибетчесе яки идән юучысы һәр көнне эш сәгатьләре бетүгә зур-зур сумкаларын көчкә өстерәп өйләренә юнәләләр. Алырдай бер әйбер булмаган кибеттән нәрсә ташыйлар соң алар?

Япь-яшь сатучылар, япь-яшь сәүдә хезмәткәрләре, райпо, универмаг җитәкчеләре—итәк астыннан товар җибәрергә ничек өйрәнделәр икән?! Алар үзләре, аларның дус-ишләре чит ил фирмалары теккән киемнәрдән генә йөри, ләбаса. Ә гади пенсионерлар —мескен картлар: «Кибетләрдә берни юк! Үлсәк—ничек җирләрләр икән?!»—дип кайгыда йөриләр.

Һәркемнең өлешенә тигән көмешен—талонына алмашка ризыгын бирә алмаслык булгач, бу талон системасын кертү нигә кирәк булды соң? Бу тәртипсезлекне, гаделсезлекне Яңа елда да дәвам итәргә уйлыйсызмы сез? Нигә ул талоннарның һәм сатарга бирелгән азык-төлекнең исәбе-саны юк? Әгәр төгәл исәп булса, безнең өлешне башкалар ашамас иде! Сез әле яшьләр, шуңа күрә искәртәсебез килә: илебезнең бик авыр елларында —моңа кадәр дә булды ул карточка системасы. Әмма мондый оятсызлыкны без күрмәдек. Әгәр сатучының урлашып түгел, ялгышып 200 грамм икмәге җитми калса, аны иң каты җәзага дучар итәләр иде.

Сәүдә җитәкчеләре, сәүдә хезмәткәрләре! Бүгенге авыр шартларда халыкның канына тоз салудан, күзгә карап мыскыллаудан туктавыгызны таләп итәбез! Сез ак халатлар, ак калфаклар киеп кенә сата торган, үзегезгә төргәкләп, тартмалап ташый торган нигъмәт-байлыкларны машина маена, буяуга, корымга, туфракка баткан кара халатлар киеп эшләүче гади халык җитештерә. Сез шуны онытмагыз!

Эшче аналар исеменнән: ВАЛИАХМЕТОВА, БИЛЬДАНОВА, ИЛЮШКИНА, ХӘЙРЕТДИНОВА, АБУТЬЕВА, ШӘЙХЕТДИНОВА, ЗИЯТДИНОВА, КВАШНИНА, СИТДЫЙКОВА, МОИСЕЕВА, ПОРФИРЬЕВА, ТОЛМАЧЕВА, СЕМЕНОВА, ФӘСХЕТДИНОВА һ.б.

РЕДАКЦИЯДӘН: Бу хатта күтәрелгән мәсьәләләр хакында җитәкче иптәшләрнең һәм гади халыкның фикерен беләсебез килә.

Безнең интервью

Хакыйкатькә юл ярып

Хәбәрдарлык җәмгыятебезнең әлегә кадәр билгеле булмаган күләгәле якларын ачты. Тормышның аяныч хакыйкате, көн итү кыенлыклары, базар экономикасына күчү, экономиканың күп укладлылыгының зарурилыгы өлкәннәр өчен генә түгел, мәктәп яшендәгеләргә дә үтеп керә. Элек бер төрле политик бәя бирелгән вакыйгаларга хәзер карашлар үзгәрә, яңара. Хәлбуки, бу үзгәрешләр мәгариф системасына, бигрәк тә аның гуманитар фәннәрен укытуга яңача якын килүне сорый. Шушы уңайдан газета корреспонденты Р. З. АЙЗАТУЛЛИН шәһәрнең өченче урта мәктәбе тарих укытучысы А. П. АЛЕМАСОВка мөрәҗәгать итте һәм бу фәнне укыту системасындагы үзгәрешләргә кагылышлы сорауларга җавап бирүне үтенде.

КОРР. Анатолий Петрович, бүгенге көндә һәр тарихи фактка караш яңара, үткәнгә ревизия ясала. Бу уңайдан сез нәрсә дияр идегез?

А. П. А. Иң башлап шуны әйтү кирәк, диалектиканың үз законнары бар, алар җәмгыять үсешенең һәр этабын объектив гәүдәләндерә. Без ул законнарны инкарь итә алмыйбыз. Укучыларга теләсә нинди теманы аңлатканда шуннан чыгып эш итәбез.

Аерым фактларга килгәндә хәл башкача, билгеле, теге яки бу вакыйгаларны чагылдырудагы хаталарны, объектив булмаган бәяләрне төзәтергә туры килә.

КОРР. Берничә буын яшьләр марксизм-ленинизм тәгълиматы нигезендә тәрбияләнде. Бүген бу теориягә тәнкыйть фикерләре еш яңгырый.

А. П. А. Хакыйкать авыр булса да, аннан берәү дә кача алмый. Ул тәгълимат теоретиклары, шул исәптән В. И. Ленин да, үзләре яшәгән чордагы иҗтимагый-сәяси хәлдән чыгып эш иткәннәр. Ул теорияне белү, бүген аңа заман таләпләреннән чыгып якын килү кирәк, чөнки бернинди тәгълимат та катып калган догма түгел.

Икенче бер нәрсәне дә онытырга ярамый. В. И. Ленин үзе дә ялгышларын таныган, кирәк икән карашларын да үзгәрткән бит. Бу—шулай ук шул чордагыны бүгенгегә турыдан-туры күчереп куярга ярамый дигән сүз. Бу мәсьәләдә борглану-сыргалану, заманага яраклашырга тырышу да булмаска тиеш, әлбәттә. Бер чиктән икенчесенә ташлану, ягъни марксизм-ленинизмны тулысынча себереп түгү объектив булмас иде. Ялгышлар зур һәм күп булды, алардан арыну, үткәнгә реаль бәя бирү зарури, ләкин социалистик идея җирдә яши һәм яшәячәк. Аның рациональ орлыкларын без сакларга, дәвам иттерергә тиешбез.

КОРР. Анатолий Петрович, базар экономикасына күчү социализмнан капитализмга борылу дигән сүз. Сез моны ничек бәялисез?

А. П. А. Бүгенге көнгә кадәр бездә социализм төшенчәсе трансформацияләнде, ягъни аның принциплары бозылды. Бу экономиканы катастрофа алдына китереп җиткерде. Моның сәбәпләре, минемчә, түбәндәгедә. Формаль яктан без бөтенесенә хуҗа булдык, ә чынбарлыкта исә бернигә дә хуҗа түгел идек. Үз хезмәтен куеп көн күрергә күнеккән крестьяннарның күбесе, урта хәлле, хәтта ярлылары да кулакка һәм кулак иярчененә әверелде, мөлкәте конфискацияләнде, үзләре сөрелде. Колхозларда хезмәткә түләүнең юк дәрәҗәсендә булуы крестьянның күңелен биздерде. Бу,үз чиратында, хуҗа булу хисе югалуга, бөтенесенә битараф карауга китерде, әхлак нормалары бозылды. Социализм милли интересларны исәпкә алмыйча, берләштерүгә, бердәм милләткә, икенче төрле әйткәндә, руслаштыруга юнәлдерелгән курс алып барды. Ә принципта социализмның асылы ирекле кешеләр җәмгыяте төзүгә юнәлдерелгән бит. Аны бозулар илебезнең төрле регионнарында иҗтимагый-сәяси хәлнең ифрат катлаулануына, милләтара конфликтларга китерде. Дәрестә укучыларга шушы хакыйкатьне, аңа китергән сәбәпләрне чынбарлык күзлегеннән чыгып аңлатырга туры килә.

КОРР. Теләсә нинди җәмгыятьтә дә төрле милләт вәкилләре аралашып яшәве табигый хәл.

А. П. А. Мин теләсә нинди шартларда да интернационалист, дусларым арасында татарлар һәм башка милләт вәкилләре дә бар. Минем өчен кешенең милләте роль уйнамый. Бу проблемага ил күзлегеннән чыгып караганда, безгә союз составында бергә һәм тату яшәргә кирәк. Экономик, политик һәм әхлак өлкәсендә дә барлык милләт халыклары өчен гомуми интереслар чагыла ич.

Бу уңайдан шуны да өсти алам, безнең мәктәптә дә төрле милләт вәкилләре укый, аларны татарга, руска, чувашка аеру мөмкин түгел. Бүгенге көнгә шөкер, балалар арасы бу сизелми.

КОРР. Бүгенге сә...
хәлләр уңаеннан э...
нинди кыенлыклар к...
рәсез?

А. П. А. Сәясәт да...
үзгәреп тора, аның арт...
нан өлгерү кыен. Дә...
ләрдә информация ч...
лары аркылы мәгъ...
булган яңалыкларга
безчә бәя бирергә т...
килә.

Дәүләт җитәкчел...
шул исәптән СССР ...
зиденты М. С. Горба...
РСФСР Президенты ...
Ельцин һәм башкалар...
кәрә торган полит...
аның үзгәреп торуы ...
нең бурычны катлау...
дыра. Хәзер бездә пар...
ләр күп, ләкин алар...
программасы, сәясә...
кыйбласы төгәл ачы...
гел. Укытучы даими...
ләнергә, үз белемен, ...
лүмлеген күтәрә бар...
тупланган информац...
гомумиләштерергә, нә...
ясарга мәҗбүр.

Ә тулаем алганда б...
өчен бер нәрсә ачык: ...
чы һәр вакыйгага ка...
объектив мәгълүмат, ...
алырга тиеш. Тарих ...
тучысы буларак, мин...
принциптан чыгып эш...

Уңган механизатор

Элек авылда гармунчыны мактаганнар: беренче егет итеп санаганнар. Ә хәзер механизатор беренчелекне яулады. Шуңадыр егетләр мәктәп эскәмиясеннән үк техникага тартылалар. Әнә Саша Аникин Сәләнгеш мәктәбенең 9 нчы классында гына укый, ә җәен «кыр корабле» капитаны Павел Александрович Корнеев янында урып-җыюда эшләде.

Павел Александрович кырда яңа кеше түгел. Аның эш стажы дистә еллар белән исәпләнә. Хәер, ул ел әйләнәсе техникадан аерылмый. Хәзер терлекчелек биналарына азык ташу белән мәшгуль. Аның тракторы да, урак өстендә ватылусыз эшләгән комбайны кебек үк, һәрчак төзек, гөрләп эшләп тора.

Рәсемдә: «Заветы Ильича» колхозы механизаторы П. А. Корнеев.

• *Депутат сүз ала*

Реаль власть кирәк

Авылда депутатның мәшәкатьләре күп төрле. Авыл халкы Советтагы үз вәкиле белән эш урынында, урамда, җәмәгать урыннарында да очраша. Сайлаучылар, табигый ки, төрле-төрле гозер белән мөрәҗәгать итәләр.

Әйтергә кирәк, Бикколдан Фома авыл Советына депутатлар үзләренә үтенеч белән мөрәҗәгать итүчеләрнең соравын канәгатьләндерү өчен тырышалар. Наказларны чынга ашыру мәсьәләсе белән дә хәл шулай, халык соравын гел истә тоталар. Минем үземә, мәсәлән, депутатлыкка кандидат чагымда, авылда балалар бакчасы булдыруда булышлык күрсәтү йөкләтелгән иде. Бу төр наказ гамәлгә ашырылды.

Безнең авыл дистәләрчә еллар читтәге бригада булып яшәде. Моннан аның хәлен аңларга була, гаиләдәге үги ул хәлендә иде. Шуңа күрә бүген күп төрле объектлар төзисе. Механизаторлар өчен җылы гараж кирәк. Яшьләр исә клуб кәтеп интегә. Депутатларга бирелгән иң мөһим һәм эре заказлар да шулар. Бу объектларда хәзер эш алып барыла. Торак йортлар салу, газ кертү белән дә шөгыльләнәбез. Авылны төзекләндерү максатыннан халыкка рәшәткәгә яраклы штакетниклар кайтартып сатылды. Пенсионерлар өчен ягулык кайтарту гаять мәшәкатьле проблема. Халыкның Советтагы вәкилләре бу мәсьәләне онытмыйлар, үз округларындагы сайлаучылар үтенечен авыл Советына, колхоз идарәсенә җиткерәләр. Чиратлап аларга ягулык кайтарыла бара.

Депутатлар шул тәртиптә эшли. Ләкин, халык сайлаган вәкил буларак, җәмәгать вазифамны башкарудан канәгать дип әйтә алмыйм әле. Һәм бу хакта беренче тапкыр гына сүз кузгатуым да түгел.

Хикмәт менә нәрсәдә. Безгә кергән күп төрле үтенеч наказларны башкару өчен Советның мөмкинлекләре бик чикле. Әйтик, мәктәпкә яисә авыл Советы карамагындагы башка учреждениегә дә ремонт кирәк. Агымдагы ел бюджетына керсә, аны хәл итү буенча нәрсә дә булса эшләргә мөмкин әле. Шуннан артыгын Совет берни дә эшли алмый, чөнки аның материаль средстволары юк дәрәҗәсендә. Акчасы булган очракта ремонт өчен билгеләнгән материалларны, мәсәлән, тактаны, яисә башка төрле әйберне кайтарырга транспорты юк. Ул ярдәм сорап колхоз рәисенә мөрәҗәгать итә. Дөрес, «Таң» колхозы җитәкчеләре—элеккесе Әнәс Нәбиуллович Рәхмәтуллин, хәзергесе Вәзир Сәлимович Сәгыйров та мондый төр үтенечләрне игътибар белән тыңлыйлар, мөмкинлекләреннән чыгып ярдәм күрсәтәләр,транспорт, акча да бүлә килделәр. Әмма хуҗалыкның үз мәшәкатьләре, чыгымнары да аз түгел ич. Бусы бер яктан. Бу мәсьәләнең икенче бер ягы да бар. Анысы, минемчә, аеруча уйландырырга тиеш: Со-
вет юридик властька ...
булса да, кулында р...
мөмкинлекләре, алда ...
телгәнчә, бик чикле. ...
нанс ягыннан да, ...
спорт мәсьәләсендә д...
хуҗалыкка бәйле. Ш...
күрә реаль власть, йо...
ты дәрәҗәсе дә бик ч...

Хәер, авылга җит...
лек формасын үзгәрт...
кында, үзидарә систем...
кертүгә хәзерлек тур...
сүз бара. Бу уңайдан...
түбәндәге фикерне ...
идем: формасы нинди...
са да авылда власть...
шында торучы орга...
—Советмы ул яисә б...
тор аппаратмы, юри...
хокукка гына түгел ...
териаль һәм башка ...
лыкларга да хуҗа бул...
тиеш. Шунсыз аның ...
власте булмаячак. ...
сыз теләсә нинди о...
исемен әллә ничек ...
куйсаң да, авыл һәм ...
бүгенге проблемал...
уңышлы хәл итә а...

Н. КӘЛИМУЛЛИ...
халык депутатлары...
Фома авыл Советы...
путаты.

Булмас димә, дөнья бу!

ИҢ ОСТА ЭЗТАБАРЛАР

Наркотикларны иң оста эзләп табучы дип, Треп исемле эт танылган. Ул Флорида штаты полицейские Том Кейзо эте. 1973—1977 елларда Треп 63 миллион долларлык наркотик тапкан.

Бер генә тапкыр да ялгышмаган Генерал исемле эт АКШ гаскәрендә хезмәт иткән. 1974 елның апреленнән 1976 елның марты арасында хәрби полициянең 591 нче ротасыннан Майкл Р. Харрис шул эт ярдәмендә 220 тентү үткәргән, наркотикларны яшереп саклаучы 220 кешене кулга алган һәм 330 яшерен саклагыч тапкан.

«Охота и охотничье хозяйство».

КОФЕНЫ БУШЛАЙ БИРМИЛӘР

Илебездә арта барган дефицит товарларга тагын берсе—кофе өстәлде.

Бу хәл көтмәгәндә генә тумады, әлбәттә. Без бер ел буена кофены бурычка эчтек, ягъни Бразилия, Һиндстан һәм башка кайбер илләр бу кыйммәтле продуктны безгә эшелоннар белән җибәреп тордылар, ә безнең ил моның өчен бер ...
дә түләмәде. Сәбәбе ...
—валюта юк. Бүген...
сәлән, безнең Брази...
кофе өчен 25 миллио...
доллар бурычыбыз ...
Шушы бурычны тү...
бәлки иртәләрен к...
эчү бәхетенә ирешә...
Әмма бу көн тиз ...
килмәс, мөмкинлекл...
бик чикле, диләр «К...
фирмасы белгечләре...

Табиблар яклау көтә

Түгәрәк өстәл артында сөйләшү

Күптән түгел «Дуслык» газетасы редакциясенең түгәрәк өстәле янында әңгәмә үткәрелде.

Әлеге әңгәмәдә район үзәк хастаханәсенең баш табибе З. А. Шабаев, баш табиб урынбасары С. Г. Пермяков, «Фармация» район производство предприятиесе директоры Н. И. Лесняков, үзәк хастаханәнең табиб-хирургы Н.М. Лисюков, район санитария-эпидемиология станциясенең бүлек мөдире Д. К. Әндәрова, Яңа Иглай фельдшерлык-акушерлык пункты мөдире Л. А. Тишкова, Кормыш авыл Советы рәисе В. Х. Шәйхетдинов, газета мөхәррире Ә. У. Абдуллин һәм редакция хезмәткәрләре катнашты. Әңгәмәдә сүз районда халык сәламәтлеген саклау эшенең бүгенгесе һәм киләчәге турында барды.

КЕШЕ үзенең сәламәтлеген иң зур байлыкка саный. Чөнки иҗатка, хезмәткә, һәртөрле эшчәнлеккә сәләтле Кеше дигәнебез еш кына ниндидер авыру алдында чарасыз калырга, ана бирешергә, хәтта тәмам өметсезлеккә төшәргә дә мәҗбүр була. Авыру-сырхау, үлем дигән явызлыклар кемнең-кем булуына карап тормый, беркемне дә аямый. Шуңа күрә, башыбызга төшсә, һәммәбез дә ярдәм эзләп аларга йөгерәбез. Менә алар— сәламәтлек сакчылары безнең белән янәшә утыралар. Заман кыенлыклары аларны да читләтеп үтмәгән. Бүгенге мәшәкатьләре, үпкә-борчулары, өмет-теләкләре белән килгәннәр алар безгә. Әйдәгез, үзләрен тыңлап карыйк.

З. А. ШАБАЕВ: Бүгенге көндә район үзәк больницасында 660 кешегә ятып дәвалану өчен мөмкинлек бар. Кайнар су, салкын су үткәрелгән. Ремонт эшләрен системалы рәвештә башкарып торабыз, кулдан килгәннең барын да эшләргә тырышабыз. Әмма дәвалану өчен мөмкинлекләр көннән-көн кими, шартлар начарлана бара. Материаль кыенлыклар хәзер адым саен үзен сиздерә. Дарулар, дәвалау җиһазлары җитми. Моңа өстәп стационар шартлары да иң гади таләпләргә дә җавап бирмәстәйгә әйләнеп бара. Алдыбызда зур-зур эшләр тора. Беренчесе—балаларны дәвалау бүлеген яңа бинага күчерү. Икенчесе—бала тудыру бүлеге өчен махсус бина төзү. Бу ике бүлек гадәттән тыш уңайсыз, начар шартларда эшлиләр. Мәсәлән, тудыру бүлегенең бүгенгәчә үз вазифаларын җиренә җиткереп үтәп килүе— шул коллектив кешеләренең тырышлыгы аркасында гына. Моны санэпидстанция вәкилләре дә белеп, аңлап тора.

Моннан тыш дәвалау-диагностика үзәге булдыру бүгенге көн өчен бик тә зарур. Һәм, әлбәттә, бу үзәк төзелсә, аның үзенә бәйле ярдәмче службалары да булачак.

Инфекцион авыруларны дәвалау бүлеге өчен махсус бина һәм үзәк район хастаханәсе өчен азык блогы төзү мәсьәләләре чиратта торалар. Дәвалаучы белгечләр юк дип зарлана алмыйбыз. Сафларыбыз ел саен диярлек тулыланып тора. Ләкин һаман да хирурглар, терапевтлар, ашыгыч ярдәм күрсәтүче табиблар, балалар табиблары җитми әле безгә. Чөнки белгечләрне материаль кызыксындырып, монда тәпләндереп калдыру өчен мөмкинлекләребез юк. Фатир ягыннан да, материаль тәэмин ителеш ягыннан да безнең медицина әһелләре үги бала хәлендә. Әйтик, 1991 елда бер гаиләне фатирлы иттек. Әмма анысы да ике бүлмәле фатирны алыштыру бәрабәренә генә эләкте. Хәзерге заманда яраткан эшләрен вәгъдә итеп кенә кадрларны тотып калу мөмкин эш түгел.

Н. М. ЛИСЮКОВ: Әйе, табиб үз вазифасы турында гына уйлап, бирелеп чын күңелдән эшләсен өчен аның җаны тыныч булырга тиеш дип уйлыйм мин. Чөнки кибетләргә кайткан товар һәм кесәдәге талоннар, йә булмаса, кеше почмагындагы вакытлыча фатирың һәм аз хезмәт хакың турында уйлар миеңә тынгы бирмәгәндә бер дә каршыңдагы кешенең кайгысын үзеңнеке итеп кабул итәсе килеп тормый шул.

В. Х. ШӘЙХЕТДИНОВ: Хак сүзләр бу. Чынлап та, бездә бер төркем оешмалар һәм предприятиеләр, үзләре товар җитештерүче булмасалар да, байларча яшиләр. Ә инде шул предприятиеләргә хезмәт күрсәтүче тармак үги бала кебек, тынсыз-сансез, мескеннәрчә яши. Әйтик, менә мисалга сөт-май, ит комбинатларын гына алыйк. Алар бит җитештерүче түгел, эшкәртүче предприятиеләр генә. Әмма үз продукцияләрен бартер юлы белән сатып дефицит товарлар алалар. Шунысы кызык: алар өчен чимал—сөт-май районның бөтен хуҗалыкларыннан килә. Ә менә бартер нәтиҗәсендә кайтарылган товарлардан комбинат үзе генә рәхәт күрә. Колхоз-совхозларны әйтмим дә инде. Шул ук сөт-май комбинаты эшчеләрен дәвалаучы табиблар да, балаларын тәрбияләучы мөгаллимәләр дә өлешсез кала. Дөресме бу?

Н. М. ЛИСЮКОВ: Әйе, без һәммә предприятиеләргә хезмәт күрсәтәбез. Әмма берсеннән дә якты йөз күргәнебез юк әле.

В. Х. ШӘЙХЕТДИНОВ: Шул ук нефтьне генә алып карыйк. Безнең аяк астыбыздагы нефтьне суырталар, төрле газлар белән агуланган һаваны сулыйбыз, ә нефтьчеләр үзләре генә байый. Мондый тигезсезлек булырга тиеш түгел, минемчә. Районыбызның хезмәте дә, байлыгы да район өчен уртак булса, дөресрәк булыр.

З. А. ШАБАЕВ: Башка нефть районнарында, мәсәлән, Азнакайда, Лениногорскида, Әлмәттә, чынлап та, бу яктан тигезлеккә омтылалар. Чөнки бу байлыкларда һәркемнең өлеше бар бит.

x x x

...Шул рәвешле әңгәмә барышында медицина әһелләре үзләренең көндәлек ихтыяҗларга кагылган мәсьәләләрен дә күтәрделәр. Аларны да аңларга була. Әгәр без югары температура белән яки сызланып, хастаханәгә дәва эзләп барганда, хөрмәтле табибыбыз җәтмә сумка күтәреп кибет буенда йөрсә, яки без ана керергә дип чиратка тезелеп көтеп утырганда ул сәгатьләр буе шикәр, он чиратында торса, бер дә күңелле булмас иде, шулай бит. Әгәр кибетләрдә талонга товар сатуны тәртипкә салмасалар, киләчәктә дә бүгенгечә башбаштаклык дәвам итсә, әлеге хәлгә таруыбыз да бик мөмкин. Һәм табибларны да гаепләп булмаячак. Чөнки алар да бит фәрештә түгел, адәм балалары. Гаиләләре бар. Безнең көндәлек ихтыяҗ—алар өчен дә табигый хәл. Мондый хәлгә калмас өчен әллә нинди үзгәртеп корулар да кирәк түгел икән үзе. «Әгәр талонга бирелә торган товарларны айга 1—2 тапкыр үзебезнең буфетта сатуны оештырсалар, яки безнең коллективка хезмәт күрсәтүне аерым бер кибеткә генә билгеләсәләр, әлеге кыенлыклар беразга чигенер иде»,—диделәр алар үзләре. Бәлки тиешле оешмалар, райпо җитәкчелеге бу зар-интизарларга колак салырлар? Алар өчен халыкка хезмәт күрсәтүне оештыру буенча эшлекле гамәли тәкъдим ләбаса бу!

Әңгәмә барышында табибларга газета укучыларыбыздан килгән хатлардагы сораулар белән танышырга һәм аларга җавап бирергә дә туры килде.

СОРАУ: Хастаханә хуҗалык исәбенә күчә дигән сүз йөри. Бу күчеш авырулар өчен тискәре нәтиҗәләр бирмәсме икән?

З. А. ШАБАЕВ: Хуҗалык исәбенә күчү коллектив эчендәге процесс ул. 1992 ел моңа хәзерлек елы гына була әле. Ә 1993 елда страховой медицина ысулына күчәрбез дип өметләнәбез. Бу күчешләр авырулар өчен тискәре нәтиҗә бирмәс. Киресенчә, авыруны дәвалауның соңгы нәтиҗәсе белән кызыксыну артачак.

СОРАУ: Медицина өлкәсендәге кризистан ни рәвешле чыгарга мөмкин дип уйлыйсыз?

С. Г. ПЕРМЯКОВ: Минемчә, иң беренче чиратта материаль яктан ярдәм кирәк. Мәсәлән, хәзерге вакытта килешүләр нигезендә түләүле хезмәт күрсәтү рәхсәт ителде. Әйтик, массаж, энә белән дәвалау очракларын алыйк. Бюджеттан тыш эшләп алу—белгеч өчен олы ярдәм бит ул.

З. А. ШАБАЕВ: Хәзер эшләргә теләгән кешегә эшләү мөмкинлеге бирелде. Сәламәтлегең, вакытың бар икән—эшлә генә. Хезмәт хакында да чикләү юк. Күпме эшләсәң—шул кадәр аласың.

СОРАУ: Бүгенге көндә аеруча нинди мохтаҗлык кичерәсез?

Н. М. ЛИСЮКОВ: Кабатлап булса да, әйтәм инде: хәтта мамык юк, бинтлар юк. Дәвалау өчен кирәк булган даруларның да 30 проценты белән генә тәэмин ителәбез.

З. А. ШАБАЕВ: Инъекцияләр өчен энәләр юк. Бер генә тапкыр файдаланырга дигән шприцларны стерильләштереп, берничә тапкыр файдаланырга да туры килә.

СОРАУ: Бу очракта СПИД куркынычын онытып торырга кушасызмы?

Д. К. ӘНДӘРОВА: Ул яклап тыныч булыгыз! Безнең районда әлегә (!) СПИД белән зарарланган бер генә кеше дә юк. Аннан соң тиешле стерильләштерү узганда энәләр дә, башка инструментлар да куркыныч түгел. Медицина хезмәткәрләренең үз эшләренә җаваплы караулары гына кирәк.

Н. М. ЛИСЮКОВ: Интенсив терапия бүлегендә эшләү хәзер аеруча кыен. Препаратлар белән беррәттән донор каны да җитми.

З. А. ШАБАЕВ: Әйе, донорлар хәзер бик аз. Быел нибарысы 1200 кешене донорлыкка өнди алдык. Үткән елларда бу сан икеләтә артык була иде. Ә югыйсә, кан кирәк, бик кирәк! Тудыру, гинекология, хирургия бүлекләре донор канына аеруча мохтаҗ.

Н. М. ЛИСЮКОВ: Донорлар саны кимүнең сәбәпләре төрле. СПИДтан курку да, донорларга игътибар юклык та сәбәп монда. Әгәр аларга ниндидер льготалар булдырсак, донорлар саны шактый артыр иде.

СОРАУ: Авыл җирләрендә нинди кыенлыклар бар?

Л. А. ТИШКОВА: Дарулар аз. Көн дә кирәк була торган иң элементарь даруларга, препаратларга да кытлык кичерәбез. Авылда бу үзен бигрәк тә сиздерә.

Н. И. ЛЕСНЯКОВ: Әйе, заман кытлыгы безне дә читләтеп үтмәде. Үз илебездә дарулар чыгару промышленносте аз үскән. Чит илләрдән кертелү кимеде. Даруларны күпләп сатып алу бәяләре узган елда ук күтәрелгән иде инде. Ә ваклап сату бәяләре элеккечә калды. Шуңа күрә аптекалар хәзер финанс ягыннан зыянга эшлиләр. Безнең чыгымнар бюджет хисабына каплана. Бүгенге көндә дарулар кытлыгын җиңеләйтү өчен бартер ысулыннан файдаланабыз. Нефтьчеләр бераз булыша. Үз көчебез белән дару үләннәре әзерлибез. Мәсәлән, быел 1 тонна 300 килограмм дару үләне әзерләдек. Валериан һәм календула үләннәрен үзебез үстердек. Бартер юлы белән умартачылык совхозларыннан томабалавыз(прополис) сатып алабыз. Бу чималдан төнәтмә, мазь ише препаратларны да үзебез ясыйбыз. Бер төркем дарулар булмаганда, сыйфат ягыннан аларны алмаштырырдай бүтәннәрен кул астында тотарга тырышабыз. Үзебезнең предприятие җитештергән дарулар да шактый. Төрле свечалар ясыйбыз. Әмма свеча составындагы какао мае чит илдән кертелгәнлектән янә дә безнең җитештерү күләме чикләнә.

С. Г. ПЕРМЯКОВ: Шикәр чире белән авыручылар өчен инсулин кытлыгы да бар бит әле.

Н. И. ЛЕСНЯКОВ. Әйе, болар безнең шартларда дәва ягыннан кыен хәлдәге авырулар. Чөнки инсулин чит илдән кертелә. Кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз инде без.

СОРАУ: Газета укучыларыбызның берсе: «Украинаның радионуклидлар белән зарарланган өлкәләреннән килгән дару үләннәрен безнең «Фитобар»да файдаланалар дип ишеттек. Моңа нишләп юл куела?» дип сорый.

Д. К. ӘНДӘРОВА: Бу сорауга мин җавап бирер идем. Чөнки дару үләннәрен дә, районга сатуга кайтарылган азык-төлекне дә махсус тикшерәбез,—радиологик контроль үткәрәбез. Әгәр нәтиҗәләрдә нормалардан тайпылыш булса, әлеге продукцияне партиясе белән кире борабыз. Мәсәлән, быел нитратлар күләме артык булу сәбәпле 4 шундый очрак булды. Шуңа күрә, кешеләр имеш-мимешләр белән үз-үзләрен борчымасыннар иде.

Н. И. ЛЕСНЯКОВ: Әйе, болары дөрес. Моннан тыш кешеләр үзләре дә үлән җыюга бик тә игътибарлы булырга тиешләр. Чөнки юл буйларында, төрле промышленность объектларына якын җирләрдә үскән үләннәр бөтен зарарлы матдәләрне үзләренә туплыйлар.

(Ахыры 4 нче биттә).

Табиблар яклау көтә

СОРАУ: Авыл җирендә яшәүчеләрнең нинди зарлары бар?

В. Х. ШӘЙХЕТДИНОВ: Бездә, мәсәлән, озаклап урында ятучыларны авыру дип тә санамыйлар. Аларга өметсез җаннар итеп кенә карыйлар. Ташлаган, беркемгә кирәксез хәлдә бу кешеләр. Һәм бу караш гадәтилеккә әверелеп бара. Авыл Советы рәисеннән башка бүтән берәү дә, шул исәптән медицина хезмәткәрләре дә, алар белән кызыксынмыйлар. Мондый «онытылган» кешеләр һәрбер авылда бар, минем белүемчә.

Шушы сөйләшүдән файдаланып, мин шәһәр предприятиеләрен һәм оешмаларын, колхоз-совхозларны хастаханәләргә материаль ярдәм итәргә өндәр идем.

С. Г. ПЕРМЯКОВ: Бу очрашудан файдаланып, минем әйтәсе килгән тәкъдимем бар. Безнең шәһәрдә мәрхүмнәрне соңгы юлга озату турында кайгыртучы бюро төзергә вакыт җитте дип уйлыйм мин. Чөнки бу мәшәкатьле эшнең үз тәртибе, гореф-гадәтләре бар. Бер якыны да булмаган кешеләр дә була. Хастаханәдә вафат булган шундыйларны үзебезгә үк соңгы юлга озатырга туры килгән чаклар юк түгел. Бу—бик җитди мәсьәлә.

Н. И. ЛЕСНЯКОВ: Сөйләшү ахырында газета редакциясе коллективына бер тәкъдимем бар иде. Газета экологик темаларга сирәк яза. Шуңа күрә билгеле бер вакыт узган саен җирле материаллар нигезендә махсус экологик сәхифә әзерләсәгез һәм аны системалы гамәлгә кертсәгез начар булмас иде.

Сөйләшү инде ахырына якынлашты. Газетаның баш мөхәррире Ә. У. АБДУЛЛИН әңгәмәдә катнашучыларга мөрәҗәгать итеп сүзне йомгаклады:

—Бүгенге очрашу, күңелдәге уй-хыялларны, теләк-тәкъдимнәрне бүлешү моңа кадәр җыелып килгән, чишелмәс тәенгә әверелгән бөтен проблемаларны хәл итү дигән сүз түгел-түгелен. Әмма әгәр без—газета хезмәткәрләре, сезнең шушы сүзләрегезне, күңел зарларыгызны халыкка, тиешле җитәкчеләргә җиткерә алсак һәм шуның белән әлеге мәсьәләләрнең хәл ителешенә әз генә уңай этәргеч, тизләтеш бирә алсак, шат булыр идек. Ә редакция адресына булган тәкъдим-киңәшләрегезне бик рәхәтләнеп кабул итәбез.

«ИРТӘН БИКЛЕ, КИЧЕН ЯБЫК

була соң ул ни өчен?—дип язалар Берлек авылында яшәүчеләр үз медпунктлары турында. —Фельдшер М.Оренбурова үзенә-үзе хуҗа. Аның эшен контрольгә алучы юк. Халык йөри-йөри дә, аптырагач 5 километрга Елаурга китә укол ясатырга. Я булмаса, больницага кереп ятарга мәҗбүр була. Матрена Оренбурованың фельдшер-акушерлык пунктын ачып халыкка хезмәт күрсәтергә теләмәве дәүләткә ничә сумга төшә икән.

Мин үзем 5 көн йөрдем укол ясатырга, ләкин пунктның ачык чагына юлыкмадым. Менә шуннан соң дәваландым диген инде. Бу эштә авыл халкына ярдәм итүче табылырмы икән?»,—дип яза сугыш һәм хезмәт ветераны Г. А. Фәтхетдинов.

Редакция хатны тикшереп чара күрү өчен район үзәк больницасының баш врачы З. А. ШАБАЕВка юллаган иде. Аңардан түбәндәге җавапны алдык.

«Баш врач ярдәмчесе С. Г. Пермяков һәм Чулпан участок больницасы баш врачы Р. Ш. Сәмигуллин составындагы комиссия Берлек-Михайловкада һәм Елаур авыллары фельдшер-акушерлык пунктларында булдылар һәм пунктларның эш сәгатен тәртипкә салдылар.

Берлек-Михайловка авылында фельдшер пенсия яшендә. Районда фельдшерларны эшкә урнаштыру вакытында Берлек-Михайловкага медицина работнигы җибәреләчәк»,—диелгән җавапта.

Рәхмәт

3 нче азык-төлек кибете сатучысы Гөлчәчәк Мөбәрәкҗановага итагатьле, культуралы сәүдә хезмәте күрсәтүе өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәбез.

Ф. НАСЫЙБУЛЛИНА,
Р. ХӘБИБУЛЛИНА,
К. ГАСИМОВ.

Тәмле аш осталары

Хәзерге кытлык заманасында районның җәмәгать туклануы предприятиесе җитештергән азык-төлек белән сәүдә итү нокталарына керсәң, җаннар рәхәтләнеп китә, муллыкка сөенәсең. Аларда предприятие ашханәләрендә, кондитер цехларында хәзерләнгән 30 дан артык төрдәге ризыклар сатыла.

Шунысы куанычлы, хәзер андый азык-төлек ризыклары район үзәгендә генә түгел, күп авылларның үзләрендә җитештерелә. Инде күп авылларда «Чәй йортлары» ачылды. Быел Яңа Әмзәдә дә эшли башлады «Чәй йорты». Иске бина яңадан корып төзелгән бу җәмәгать туклануы ноктасы хәзер кешеләрнең ял итү урынына әверелде. Якын арада шундый «Чәй йорты» Кыткаклыда да ачылачак.

Әйе, бүген базар мөнәсәбәтләренә күчү бусагасында торганда кешеләрнең күңелен табу, аларга тәмле, ләззәтле ризыклар тәкъдим итү үзе бер матурлык.

Фома авылындагы «Чәй йорты» районда гына түгел, тирә-як төбәкләргә дә билгеле. Анда эшләүчеләрнең уңганлыгы, ягымлылыгы, аш осталары турында язып чыкканыбыз бар инде. Зәвык белән бизәлгән чиста, якты зал кешеләрне үзенә тартып тора. Зөлфия Хәйбуллина кул астында (ул бригадир) эшләүчеләр һәркемне ачык йөз белән каршылап, тәмле ашамлыклардан авыз итәргә чакыралар. Биредә пешерелгән ризыкларны һәркем яратып ала. Туйга дигән савым ашларын да якын-тирә халкы шунда гына пешертеп ала. Үзләрендә үк яшьләр кичәләре, төрле мәҗлесләр дә үткәрә Фома кешеләре.

Ә бригадир Зөлфиягә килгәндә, ул инде биредә яңа кеше түгел, «Чәй йорты» ачылган көннән бирле хезмәт куя. Гаиләсе булса да күп вакытын биредә уздыра ул. Чөнки коллектив зур булмаса да яшь кадрлар да, өйрәнчекләр дә булып тора. Аларга күз-колак булырга, ярдәм итешергә кирәк бит.

Буфетчы кыз Гөлфия Гыйльфанова биредә яңа кеше. Белгечлеге дә башка. Ул элемтә техникумын тәмамлаган, әмма профессиясен үзгәртергә туры килгән. Хәзер ул «үз урынында» дияргә була. Шул ук бригадирлары булышлыгы белән аш серләренә төшенеп килә. Буфетны зәвык белән бизи, һәрнәрсә үз урынында, кешеләр белән мөнәсәбәте дә әйбәт. Тикмәгә генә районда үткәрелә торган аш-су осталары конкурсында катнашып призлы урыннарны алмый ул.

Рәсемнәрдә: (өстә) бригадир З. Хәйбуллина һәм аста—буфетчы кыз Г. Гыйльфанова.

Н. Азизов фотолары.



Гаҗәп хәлләр

ХИСОР КЫШЛАГЫНДА

Гиссар районының Хисор кышлагында яшәүче Усманхан Рәхмәтовның зур өе 12 минут кына янды. Колхозның янгын сүндерүчеләре килгәндә аннан көл генә калган иде инде. Әгәр ул факт документлар ярдәмендә расланмаса, ялкынның барлык корылмаларны шундый рекордлы вакыт эчендә юк итүенә ышану авыр булыр иде. Янып каралган стеналарны караганда, беренче булып, күңелгә биредә эш «кара көч»ләрсез булмагандыр дигән уй килә. Һәм мондый фикер нигезсез дә түгел.

Гадәти булмаган вакыйгалар Рәхмәтовлар гаиләсенең күнегелгән тормыш агышын күптән бозып килә иде инде. Әмма соңгы вакытта өйдә акылга сыймаслык хәлләр була башлады. Бервакыт өй түбәсенә ташлар ташкыны яудыралар. Хуҗа күрше малайлар шуклананалардыр дип ишек алдына йөгереп чыга. Шул чак аның янәшәсеннән авырлыгы 3 килограммлап булган таш очып үтә. Әйләнеп караса, янында беркем дә юк. Түбәгә менсә, анда бик күп ташлар күрә. Алар юылган кебек, тузансыз.

Чираттагы һөҗүм тәрәзәләргә юнәлтелә. Бер генә бөтен пыяла да калмый: Кешеләр хәер-сәдака бирергә, күршеләрне ашка чакырырга, ә чакырылмаган квартирантның күңелен йомшартырга киңәш итәләр. Дингә ышанучылар Коръәннән саклык догалары күчереп язарга һәм аларны өйдә элеп куярга киңәш бирәләр. Бер атна дәвамында тыныч була, аннары таш ташкыны яңадан көчәя.

Мондый хәлләр Усманханның тенкәсенә тия. Бервакыт ул, күңеле тарып тулганда, шашынып кычкырып җибәрә: «Син миңа таш бәрсәң, ә мин сиңа пычак тондырам». Бу сүзләр «пәри»гә ошамады булса кирәк—бөтен ишекләр дә тупсаларыннан алынган булып чыга. Хуҗалар аларны яңадан урыннарына куялар һәм ишек алдына чыгалар. Озакламый алар көчле тавыш ишетәләр. Бер ишек яңадан урыныннан куптарылып алынган булып чыга. Рәхмәтов күрше бүлмәгә күз сала һәм түшәмдә зәңгәр төстәге, тенсез ниндидер гадәти булмаган ялкын котырынуын күрә.

Җирле властьлар янгынга дучар булучыларны аңлап эш итәләр, ниндидер мистика, шайтан эше дип кул селтәмиләр. Алар гаиләгә вакытлы торак бирәләр. Ләкин яңа урында да нинди дә булса әйбер, көтмәгәндә дөрләп янып китә.

Хисор кышлагындагы хәл белән Таҗикстанның төрле аномаль күренешләрне өйрәнүче галимнәре дә кызыксындылар. Алар Рәхмәтовлар гаиләсен, бигрәк тә балаларын, күзәтә башладылар. Чөнки полтергейст гадәттә үсмер һәм яшь чакта юлдаш була бит. Тик гаиләне шайтан михнәтләреннән ничек коткарырга?

(ТАСС).
Таҗикстан ССР.

Әниебез Суфия Кәлимулла кызы Шакировага 55 яшь тула. Сөекле әниебезне юбилее белән котлыйбыз, аңа тыныч тормыш, сәламәтлек, озын гомер телибез.

КИЯВЕ, КЫЗЫ, ОНЫКЛАРЫ.

МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.

Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.
Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Нурлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге—2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
ТССР информация һәм матбугат Министрлыгының Нурлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак.
Заказ 153.
Тираж 3413.